**Ни кызганыч, арабыздан инде**

**Мәңгелеккә китеп бардыгыз....**

**Тик күңелгә онытылмый торган**

**Җыр – моң булып кереп калдыгыз!**

# Якупова
# Рокыя Якуп кызы



Әнием, Якупова Рокыя, 40 ел гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлады.



Ул 1924 елда Юлбат авылында туган. 1932-1935 елларда Юлбат башлангыч мәктәбендә, 1936-1939 елларда Сатыш җидееллык мәктәбендә белем ала. 1940-1942 елда Саба урта мәктәбендә укый. Аны тәмамлаганнан соң, 1942 елда, хезмәт юлын Сатыш җидееллык мәктәбендә тарих укытучысы буларак башлый. 1943-1945 елларда Килдебәк, 1946-1947 елларда Тимершык җидееллык мәктәпләрендә укыта. 1949 елда читтән торып Казан педагогия училищесын тәмамлый. 1948 елдан лаеклы ялга киткәнче (1981 ел), Тенеки башлангыч мәктәбендә укытучы һәм мәктәп мөдире булып эшли.

1947 елда “1941-1945 елларда тылдагы фидакярь хезмәт өчен” медале белән бүләкләнә. Хезмәт ветераны.

1992 елда вафат булды.

Улы Сафин И.Ф. сөйләгәннәрдән



# Чутаева
# Шәмсия (Шәмсебану)
# Хәлиулла кызы

Арча контоны Сәрдек волосте Күкшел авылында хәлле крестьян гаиләсендә 1910 елның 15 августында туган.

“Без семьяда 11 бала үстек. Әтинең кечкенә генә 6 почмаклы йорты, 1 сыер, 1 аты бар иде. Әти итек басты. Абыйларны да шул эшкә өйрәтте. Җәй буе басуда булдык. Кышын ирләр итек бастылар. Әти, итекләрне ат чанасына төяп, атналар буе сатып йөрде.

Революциядән соң әтине кулак дип (1930 ел), төрмәгә алып киттеләр, йортыбызны контора иттеләр. Әниләр кечкенә балалар белән мунчада яши башлады. Мин бу вакытта укуда идем. Абыйларны кулак балалары дип колхозга алмадылар. 7 ир туганым Киров өлкәсендә төрле эшләрдә эшләделәр. Мин бу вакытта Кукмара районының Сәрдек авылында укыта идем, ә мине кулак кызы дип укытучылыктан кудылар. Сәрдектән киткәч, РОНО мөдире чакырды һәм Мамадышка 3 айлык укытучыларның белемен күтәрү курсларына барырга кушты. Син укытучы һөнәрен ташларга уйлама, укып кайтканчы бәлки дөньялар үзгәреп куяр, диде. Курслар беткәч, миңа Саба районына кайтырга тәкъдим иттеләр. Саба районында укытучыларга кытлык, диделәр. Мин үзем дә Кукмарага кайтырга атлыгып тормый идем. Саба районына килгәч, Шекшедә 1 ел, Туктар башлангыч мәктәбендә 6 ел, 1937 елдан Юлбат башлангыч мәктәбендә пенсиягә чыкканчы укыттым.

Эш дәверендә РОНО тәкъдиме белән район башкарма комитеты члены итеп сайладылар. Татарстанның алдынгы укытучыларның 1 нче съездына җибәрделәр.”

Тыл ветераны. “Почет билгесе” ордены, “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнә. Әни 1999 елның 8 февралендә вафат булды.

Әнисенең истәлек дәфтәреннән улы
Абдуллин Хашим язып бирде.




## Галләмова
## Зәйнәп Галләм кызы

1924 елның 17 июнендә Юлбат авылында туган.

Озак еллар кошчылык фермасында эшли, 1956 елда ВДНХга бара. “Ворошилов” исемендәге колхозда эшләгән.

Тыл ветераны. 1972 елда “Почет билгесе” ордены; Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60 еллык юбилей медальләре, 1970 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2010 елның 9 сентябрендә вафат булган, Юлбат авылына җирләнгән.



## Мәрданова (Гайфуллина)
## Гөлшикәр Гайфулла кызы

1914 елда Юлбат авылында туган.

“Ирләр сугышка киткәч, авылдагы барлык эшләр хатын-кыз җилкәсенә калды. Мин үзем лобогрейкада эшләдем. Ашарга юк, ачка үлмәслек көндәлек ашау, шул көе бер караңгыдан, икенче караңгыга чаклы эшлисе. 1943 елның кышында Апас районы Йомралы авылы янында окоп казуда булдык. Кәбир абый, Гыйният абый, Габделбәр абый, Шәймәрдән Әлмие, Бадиков Сабир, Гайниҗамал, Галләм, Гамбәр, мин - 9 кеше бер группада идек. Авылдан 12 км барып эшләдек, кич алтысыз кайтмый идек,” - ди.

“Ворошилов” исемендәге колхозда эшләгән. Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең юбилей, 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.

1997 елның 20 сентябрендә вафат. Юлбат авылында җирләнгән.



## Галимуллина Шәмсениса Галимулла кызы

1918 нче елда Юлбат авылында туа. Яшьлеге авыр сугыш елларына туры килә. 1940 нчы еллар тирәсендә Донбасс шахтасына вербовать ителеп, эшкә җибәрелә. Сугыш башлангач, авылга кайта. Сугыш чорында тракторда эшли. Сабага трактор ремонтларга җәяүләп менеп йөрүләре турында еш искә ала иде.

Галимуллина Шәмсениса колхозның да иң авыр эшендә – гомере буе фермада эшли. Башта - дуңгызлар, аннан бозаулар карый. Ул вакытта фермадагы барлык эш кул хезмәте белән башкарыла. Авыр хезмәт, ачлы-туклы тормыш, нужалы еллар ул чор хатын-кызларының сәламәтлеген нык какшата.

Тыл ветераны. 1946 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

1996 нче елда Шәмсениса әби бакыйлыкка күчә. Юлбат авылына җирләнгән.



## Таҗиева (Гайфуллина) Фатыймабикә Гайфулла кызы

1916 елның 4 январенда Шекше авылында туган.

Тракторчы булып, Юлбатка эшкә килгән һәм авылда төпләнеп калган.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен”, “В.И.Ленинның 100 еллык юбилей” медальләре белән бүләкләнгән.

1996 елның 20 октябрендә вафат булган. Юлбат авылында җирләнгән.



# Мифтахова (Ибраһимова) Гыйлемсара Ибраһим кызы

1912 елда Саба районы Югары Утар авылында гаиләдә дүртенче бала булып дөньяга килә. Башлангыч һәм җидееллык белемне туган авылында ала.

1937 елларда Саба районы МТС карамагында хатын- кызлардан торган трактористлар укуы оештырыла. Шул курсларны бетереп, тракторчы булып эшли башлый. Төрле хуҗалыкларда эшлиләр. Булачак тормыш иптәше белән шунда очраша. 1938 елда Юлбат егетенә тормышка чыга. Тормышка чыккач та әле тракторист булып эшли, чөнки бу еллар сугыш чорлары була. Тормыш иптәше Мифтахов Садретдин МТСта бригадир булып эшли.

Гыйлемсара, пенсия яшенә җиткәнче, колхозның төрле тармакларында эшли. Гаиләдә дүрт балага тормыш бүләк итәләр. Ике баланың үлемен дә кичерергә туры килә. Калган ике баласы да Хәнәфия һәм Мөршидә, “Искра” колхозында хезмәт куеп, лаеклы ялга чыктылар. Гыйлемсара, малае Хәнәфия һәм килене Гөлчирә гаиләсендә хөрмәтле әни, оныклары, өч кызның кадерле әбисе булып, 1994 елны бакыйлыкка күчте. Юлбат авылында җирләнгән.

Тыл ветераны, Бөек Җиңүнең юбилей, 1948 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.



# Хисамиева (Хәбибуллина) Өммикамал Хәбибулла кызы.

1915 елнын 12 февралендэ Саба районы Тенеки авылында туган. Сугыш вакытында Апас районында окоп казуда, урман кисүдә эшләгән. Төннәрен фронт очен носки, бияләй бәйләгән. Колхозда төрле авыр эшләрдә эшләгән.

2003 елнын 19 гыйнварында 87 яшендэ вафат булган. Тенеки авылына җирләнгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.



# Хаҗиева Рәшидә
# Хаҗиәхмәт кызы

Әнием 1923 елның 15 маенда Юлбат авылында Хаҗиев Хаҗиәхмәт һәм Маһиҗиһаннар гаиләсендә 12 нче бала булып дөньга килә.

1930-1933 елларда Юлбат башлангыч мәктәбендә,1933-1936 елларда Сатыш җидееллык мәктәбендә, аннары 1936-1939 елларда Саба урта мәктәбендә белем ала. 1940 нчы елда Казанда немец теле укытучылары хәзерли торган курсларны тәмамлый. 1947-1951 елларда Казан Дәүләт Укытучылар Институтының татар теле һәм әдәбияте бүлегендә укый. 1940-1942 нче елларда Әгерҗе районы Көчек авылында немец теле укыта, аннары үз ягына Саба районына кайта. Бер ел Килдебәк җидееллык мәктәбендә немец теле укытып, 1943 елда Сатыш җидееллык мәктәбенә немец теле, татар теле, биология укытучысы итеп билгеләнә. Мәктәпнең комсомол секретаре дә була. Сугыш чоры булса да, тормышлар авыр булуга карамастан мәктәпләрдә укулар дәвам итә.


Юлбаттан Сатышка җәяүләп төшәләр, кечерәк балаларны арка кочтырып алып төшә торган була ул. “Балаларның өсләре кырык ямаулы, ачлы-туклы. Әмма дәресләр бара. Ни дәфтәр, ни дәреслек, ни язу карасы юк. Ни туры килсә шунда язабыз, бер карандашны 3-4 кә бүләбез”,- дип сөйли торган була.


1951 елның 18 мартында әтиемә, Сатыш авылы егете Габдрахманов Габдрәүф Габдрахман улына кияүгә чыга. 5 бала тәрбияләп үстерделәр. Балаларының барысы да югары белем алып, төрле тармакларда эшлиләр.

Әнием, Хаҗиева Рәшидә Хаҗиәхмәт кызының хезмәтләрен хөрмәтләп Бөек Җиңүнең 30, 40 еллык Юбилей, “В.И.Ленинның 100 еллык юбилей”, 1952 елда “За трудовое отличие”, 1945, 1947 елларда бирелгән “ За доблестный труд в Великой Отечественной войне”, 1967 елда “Ана даны” медальләре белән бүләкләнгән. 1977 елның 22 сентябреннән Тыл ветераны.



Әнием - сугыш елларын кичкән миллионлаган тыл хезмәтчәннәренең берсе. Сугыш чорының барлык авырлыкларын үз җилкәсендә күтәргән япь-яшь кыз. Сугыш елларында язылган көндәлеге саклана. Бу көндәлектә кемнең, кайчан сугышка киткәнен, тылдагы тормышның авырлыгын, фронт яңалыкларын язып бара. Әнием көндәлеге – тарихи ядкарь. Без аны кадерләп саклыйбыз.





**Көндәлектән тылдагы тормышның авырлыгын тасвирлаган кайбер җөмләләр:**


6 май, 42 ел. Тормыш авыр, икмәк юк, шулай булса да, сугыш вакыты булгач, түзәргә туры килә. Он 2400 сум, бәрәңге 400-600, май 160-170 сум.

19 октябрь, 1943 ел. Халыкның тормышы чиктән тыш авыр. Он, ипи күргәннәре юк. Күп кешенең алабута, бәрәңгесе дә юк. Түләүләр бик күп.

Озак еллар Сатыш урта мәктәбендә татар теле һәм немец телләре укытып, 1974 нче елда пенсиягә чыкты.

1993 нче елның 18 нче гыйнварендә вафат булды.

Кызы Мәҗитова Р.Г. сөйләгәннәрдән.



## Гайфуллин
## Вәлимөхәммәт  Гайфулла улы

1931 елның 18 февралендә Саба районы Юлбат авылында туган. Авылда тире жыючы булып эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2002 елның 12 июлендә вафат булган. Юлбат авылында җирләнгән.




## Хаҗиев
## Муллаәхмәт Хаҗи улы

1932 елның 19 августында Саба районы Юлбат авылында туган. “Искра” колхозында төрле эшләрдә эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2015 елның 15 октябрендә вафат булган. Юлбат авылында җирләнгән.



## Габделхәев
## Насих Габделхәй улы

1932 елның 6 мартында  Саба районы Юлбат авылында туган. Гомер буе “Искра” колхозында шофер булып эшләгән.

Тыл ветераны. 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2003 елның 13 августында вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.



## Шәрифуллин Нурулла Шәрифулла улы

1931 елда Саба районы Юлбат авылында туган.

“Искра” колхозында, соңгы елларда Юлбат мәктәбендә завхоз булып эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

1996 елның 18 августында вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.



## Хәлилов Сәетгәрәй Хәлил улы

1928 елның 1 мартында Саба районы Юлбат авылында туган. Гомер буе “Искра” колхозында эшләгән.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

1995 елның 22 мартында вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.



## Халиков
## Мөхәммәтхан Халик улы

1929 елның 22 декабрендә Саба районы Юлбат авылында туган.

Умартачы булып эшләгән.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2007 елның 5 июнендә вафат була. Юлбат авылына җирләнгән.



## Мәрданов Хәбибрахман
## Фәйзрахман улы

1932 елның 7 мартында Саба районы Юлбат авылында туган. “Искра” колхозында тракторчы булып эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2012 елның 19 декабрендә вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.



## Галимҗанов
## Хәниф Галимҗан улы

1928 елның 27 июнендә Саба районы Юлбат авылында туган. “Искра” колхозында эшләгән.

Тыл ветераны. 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2009 елның 9 ноябрендә вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.



## Таһирова (Сәләхиева) Мосалия Сәләхи кызы

1921 елның 1 октябрендә Саба районы Керәнне авылында туган.

“Ворошилов” исемендәге колхозда төрле эшләрдә эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

1997 елның 28 декабрендә вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.



## Фәрхуллина (Фәхретдинова) Хәтирә Муллахмәт кызы

1914 елның 5 мартында Саба районы Туктар авылында туган.

1934 елда Юлбат авылына килен булып төшә.

Колхозда төрле эшләр башкара.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2000 елның 28 ноябрендә бакыйлыкка күчә.



## Сәйфуллина (Шәйдуллина) Раушания Шәйдулла кызы

1930 елның 15 июлендә Саба районы Мәртен авылында туган.

“Искра” колхозында пешекче булып эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2001 елның 3 сентябрендә вафат булган. Йосыф - Алан авылына җирләнгән.



# Гомәрова (Җәләлиева) Мәхтүмә Җәләли кызы

Минем әбием, 1912 нче елның 4 октябрь көнендә Тенеки авылында эшче гаиләсендә туган. Гаилә ишле-12 бала булган. Алар, барысы да кечкенәдән кул арасына кереп, эшкә өйрәнеп үскәннәр. Мәктәпләрдә уку насыйп булмаган. Тормышларның бик авыр вакытлары булган бу. Гаилә башлыгы - әбиемнең әтисе Җәләли бабай - бик тырыш, уңган, эш сөючән кеше булган. Гаиләсен ач-ялангач итмәс өчен тырышып көн иткән, нык тормыш булдырган. Аларның ишеген кайгы шакыган. “Авылның хөсетле кешеләре безнең ару тормышыбыздан көнләшеп жалу биргәннәр”, - дип сөйләде миңа әбием. Яман кешеләр сүзенә ышанып, аларның бар байлыкларын тартып алганнар. Ак келәт, ике сыер, ике ат, сука, тырмалар һәм башка бик күп кирәк-яракларны тартып алганнар алар.

Гаилә тырышып яшәвен дәвам иткән. Уллар, кызлар үсеп җиткән. Мәхтүмә әбием җитү кыз булган. Тенеки авылының иң сылу, уңган кызын күзләүчеләр дә табылган. Шушы ук авылның иң гаярь, батыр егете - Госман бабам аны гомерлек яр иткән. Алар, үз көчләре белән йорт салып, матур гаилә булып яши башлаганнар. Менә аларның уртак җимешләре-балалары туа башлаган. Ике ир бала-Габдулла белән Мөҗәһит абыйларым ишек алдындагы хәтфә үләндә тәгәрәп үсәр вакытта илгә афәт килгән. Сугыш!!! Бу сүз олы кешеләрне генә түгел, ә бәлки сабыйларны да тетрәтә. Әтиләре сугыш кырына чыгып киткәндә, ике бала әбиемнең итәгенә ябышып елап кала. Авыр сугыш вакыты, аларның балачагы урланган еллар мәңгелеккә аларның күңеленә уелып кала.

Әбием, ике улын тәрбияләү өстенә, бер генә көн дә авыр хезмәттән калмаган. Тырышып эшләгән, алны-ялны белмәгән. Җиңү көнен якынайту, кадерле ирен, газиз туганнарын күрү теләге көчле булган аның (Зәкәрия, Кәшиф исемле абыйлары сугышта хәбәрсез югалганнар, ә Хәйретдин,

исемле абыйлары кайту бәхетенә ирешкән). Шул теләк авырлыкларны җиңәргә булышкан, сынмаска, сыгылмаска өйрәткән. Сугыш башланып, авылдагы кыр эшләре бераз җиңеләю белән, 30 кешене Буа ягына окоп казырга җибәргәннәр. Алар арасында минем әбием дә булган. “Ачык булган вагоннарга утырып, Буа дигән шәһәрдән арырак алып барып җиткерделәр”,- ди әбием. Шунда ярты ел дәвамында окоп казыганнар алар. Андагы газаплы тормыш, авыр хезмәт турында әбием еламыйча сөйли дә алмый иде. Әбием бөтен саулыгын шунда югалтып кайта. Нык салкын тиюдән аның аяклары йөрүдән туктый һәм ул озак вакытлардан соң гына култык таяклары ярдәмендә йөри башлый. Бик авырлык белән, әкренләп аякка баса ул. Ул еш кына: “Ике сабыем хакына исән калганмындыр мин,” - дия торган иде.

Тормыш дәвам итә. Гаилә башлыгы - Госман бабам - авыр яралар алып, сугыш кырыннан кайта. Шатлыкның иге-чиге булмый!

Бу тату гаиләдә бер-бер артлы Фәүзелҗинан, Мөслимә, Раян, Нәсимә, Әкълимә, Ибраһим исемле балалар дөньяга килә. Куанып яшисе дә яшисе генә. Ләкин, янә кайгы ишек кага. Бабам сөкле хатынын, кадерле балаларын калдырып вафат була. Тормыш терәге булган ирен югалткач та, әбием югалып калмый, теше-тырнагы белән эшкә тотына. Аның иң зур теләге балаларын кеше итү була. Тырышлыгы бушка китми. Аның һәр баласы да тормышта үз юлларын табалар, гаилә корып, балалар үстерәләр.

Авыр тормыш юлы узып, сынмыйча, сыгылмыйча үрнәк булып яши белгән, илгә лаеклы уллар, күркәм кызлар үстергән әбиемне чын ветеран дип әйтми мөмкин түгел.

Сугыш ветераны дип тә аталырга лаек ул. Чөнки сугыш аны вакытсыз тол, ә балаларын ятим иткән. Баһадир гәүдәле ике ир туганын күрә алу бәхетеннән мәхрүм калдырган.

Тыл ветераны ул. Тылдагы авырлыкны үз җилкәсендә татыган. Сыгылган, чүгәләгән, егылган, торып киткән. Җирдә яшәү аны көчле иткән.

Хезмәт ветераны да ул. Гомере буе тырышып хезмәт иткән. Гомеренең соңгы көненә кадәр булдырган мул тормышын юктан бар иткән.

Әбием картлыгында, балаларының җылы канаты астында, төпчек улы-минем әтием тәрбиясендә бик бәхетле гомер итте. Тормышның муллыгына, гомер иткән йортының иминлегенә, балаларының саулыгына сөенеп, үткәннәрен барлап, киләчәкнең тагын да матуррак булачагына ышанып, 97 яшендә мәңгелек йортына күчте.

Тыл ветераны, 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнә.

Оныгы Гомәров Азат Ибраһим улы




# Шәмсиев
# Һарун Шәмси улы

1931 елның 6 февралендә Саба районы Юлбат авылында туган. Гомер буе “Искра” колхозында бухгалтер булып эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2009 елның 25 августында вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.



# Нуретдинов Нургаян
# Нуретдин улы

1926 елның 21 мартында Саба районы Калатау авылында туган. “Искра” колхозында эшләгән.

Тыл ветераны. 1985 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2011 елның 1 июлендә вафат булган. Калатау авылына җирләнгән.



# Рәшитов
# Равил Рәшит улы

1934 елның 14 августында Саба районы Йосыф - Алан авылында туган.

“Искра” колхозында төрле эшләрдә эшләгән.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2005 елның 4 маенда вафат булган. Йосыф - Алан авылына җирләнгән.



# Шляпина
# Сәлимә Абдрахман кызы

1924 елның 4 апрелендә (кыз фамилиясендә кала) Әгерҗе районы Иж-Бубый авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1941 елда туган авылында урта мәктәпне тәмамлый, Казанга укырга китәргә хыяллана. Сугыш аның бу хыялын чынга ашыруга киртә була. Сәлимә авылда кала. Окоп казуда (Апас районында), урман кисүдә, юллар чистартуда катнаша. Зенитчылар әзерли торган курсларда укый.

1943 елда ул Алабуга укытучылар хәзерли торган торган институтка укырга керә. 1945 елда уңышлы тәмамлап, Саба районына эшкә җибәрелә. Педагогик хезмәтен ул Саба урта мәктәбендә татар теле укытучысы буларак башлый. 1946-51 елларда Төбәк җидееллык мәктәбендә эшли.



1950 елда Юлбат егете Сәләхов Ясәвигә тормышка чыга. Ире Ясәви белән дүрт бала тәрбияләп үстерәләр.

1951-54 елларда Сатыш урта мәктәбендә татар теле укыта. 1955 елда Юлбат башлангыч мәктәбенә күчә һәм лаеклы ялга чыкканчы (1979 елга кадәр), авыл мәгарифен үстерүгә үзеннән өлеш кертә.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.

2007 елның 13 июнендә вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.



# Дәүләтшина (Габдрахманова)
# Рауза Габдрахман кызы

1910 елны Юлбат авылында туган.

“Ворошилов” исемендәге колхозда эшләгән.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

1981 елның 30 сентябрендә вафат булган.



## Ганиева (Сәләхетдинова) Мөкәррәмә Сәләхетдин кызы

1917 елның 17 январендә Саба районы Тенеки авылында туган. Сугыш елларындагы барлык авырлыклар белән очрашып, кырчылык бригадиры, соңыннан ферма мөдире булып эшли.

Тыл ветераны. “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнә. Сугыш чорының түгәрәк даталарына бирелгән медальләргә лаек булган. 2002 елның 12 ноябрендә вафат булган. Тенеки авылына җирләнгән.



## Габдрахманова (Галиҗанова) Гамбәр Галиҗан кызы

1924 елның 1 декабрендә Юлбат авылында туган.

“Ворошилов” исемендәге колхозда төрле эшләрдә эшләгән.

Тыл ветераны. 1946 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнә. Сугыш чорының түгәрәк даталарына бирелгән медальләргә лаек булган.

2002 елның 17 октябрендә вафат булган. Тенеки авылына җирләнгән.



## Зәйнуллина (Габдрахманова) Рәйсә Габдрахман кызы

1932 елның 19 ноябрендә Саба районы Калатау авылында туган. “Искра” колхозында төрле эшләрдә эшләгән, фермада бозаулар караган.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2005 елның 27 августында вафат булган. Калатау авылына җирләнгән.



## Зәйнуллин
## Нәкыйп Сәйфулла улы

1931 елның 31 январенда Саба районы Калатау авылында туган. “Искра” колхозында бик озак тегермәнче булып эшләгән. Балта остасы да булган.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2001 елның 1 январенда вафат булган. Калатау авылына җирләнгән.



## Мусин
## Габделбәр Җиһанша улы

1931 елның 24 ноябрендә Саба районы Аккүл Бигәнәй авылында туган. Ил өстенә килгән олы афәт - сугыш башланганда, аңа 10 яшь булган. Ир - ат башкара торган авыр эшләр аның җилкәсенә төшкән. Яшь булса да, ачлы-туклы килеш басуда урак та урган, урманын да кискән, лабогрейкада да эшләгән.

3 ел Совет Армиясе сафларында Германиядә хезмәт иткән. Армиядән кайткач, колхозның барлык авыр эше аның куллары аша узган. Гомер буе балта остасы булып эшләгән.

Армиядән кайткач, Хәдичә апа белән гаилә корганнар. 4 кыз бала тәрбияләп үстергәннәр.

Тыл ветераны. 1948 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2016 елның 6 февралендә вафат. Йосыф-Алан авылына җирләнгән.



## Хөсәенова (Сафиуллина) Халисә Сафиулла кызы

1908 елның 7 январенда Буа районы Әлки авылында туган, балалар йортында тәрбияләнгән. 1942 елның март аеннан лаеклы ялга чыкканчы, Йосыф - Алан авылында 35 ел укытучы булып эшләгән. Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнә. Сугыш чорының түгәрәк даталарына бирелгән медальләргә лаек булган.

1993 елның 21 февралендә вафат булган. Йосыф - Алан авылы җирләнгән.



## Хатипова Шәфига Хатип кызы

1926 елның 5 июнендә Югары Шытсу авылында туган.

1962 елдан 1983 елга кадәр Йосыф - Алан мәктәбендә укытучы булып эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнә. Сугыш чорының түгәрәк даталарына бирелгән медальләргә лаек булган.

2014 елның 1 декабрендә вафат булган. Йосыф-Алан авылына җирләнгән.



## Хаева Тәнвирә Мөбәрәкҗан кызы

1927 елның 4 мартында Саба районы Йосыф - Алан авылында туган.

Гомер буе хат ташучы булып эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2010 елның 11 декабрендә вафат булган. Йосыф - Алан авылына җирләнгән.



# Саттаров
# Фоат Кәшип улы

1929 елның 26 нчы ноябрендә Саба районы Йосыф – Алан авылында Кәшип белән Мәймүнә Саттаровлар гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килгән. Гаиләдә бабамның тагын дүрт туганы булган. Алар - утлы елларда ачлык- ялангачлыкны татып үскән балалар. Әтисе сугышка киткәндә, аңа 12 яшь булган. Бабам 7 класс белем алган. Почтальон булып эшләгән. Сатыштан авылга газета-журналлар ташыган. Шулай ук яшь булуына карамастан, урман кисүне дә татырга туры килгән.

Япь-яшь егет-кызларга көн күрүләре бик авыр булган. Жиңү өчен бар тырышлыкларын куйганнар. Кыскасы, тылда эшләгәннәр барысы да фронт өчен булган .

Бабамның әтисе сугыштан әйләнеп кайтмый. Бу алар өчен ачы хәсрәт була.

Бабам Арчада механизаторлыкка укый. Күп кенә еллар «Искра» колхозында тракторчы булып эшли (1959—1973 еллар). Аңа тагын урман бригадиры булып эшләргә дә туры килә (1973—1985 еллар). Ләкин урманда агач аударганда, аягына агач төшеп аягын сындыргач, ул эшенә кире бара алмый. Аңа колхозга хисапчы эшенә кайтырга туры килә. Әйтик, үчәүдә икмәк төягән машиналарны, силос, сенаж салганда кайткан яшел массаны үлчәп торган. Мин дәү бабамны чиксез хөрмәт итәм. Кызганычка каршы, ул бүген вафат инде. Калатау авылына җирләнгән. Мин олы горурлык белән: “Бабам миңа тыныч тормыш бүләк иткән”, - дип әйтә алам.

Бу язмамны Фоат бабамның кызы Рузилә - минем әбием сөйләве буенча яздым.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнә.

Оныкчыгы Дәүләтшин Рифнур.



# Фатыйхова (Хәмидуллина) Газанбану Хәмидулла кызы

1907 елның 21 маенда Саба районы Урта Саба авылында 2 нче бала булып дөньга килә. Тормышлары бик авыр була. Бик яшьли этисе үлеп китә. Әнисе этисенең энесенә кияүгә чыга. Яңадан 2 кыз бала туа (Шәмселхәят, Хәерлбанат).

Дәү әни (без аны дәү әни дип йөрттек) Юлбат авылына, Фатих бабайга кияүгә чыга. Аларның бер- бер артлы 4 балалары туа. Ләкин алдагы 3 баласы: Кәшиф, Назиф, Зөбәрҗәт кыска гомерле булалар. Соңгы 4 нче баласы - минем этием Вазыйх (1940 елгы) кына аңа таяныч булып кала.

Дәү әниләр хәлле семья була. Аларны 1931 елда Саба районы башкарма органнары тарафыннан йорт - җиреннән, мал мөлкәтеннән мәхрүм иткәннәр. Шул чорларны искә төшергәндә, дәү әнинең күзләреннән бер дә яшь кипмәде. “Өйдә нәрсә бар барсында алып чыгып киттеләр. Яшерә алганнарын яшереп калдым. Яшерә алмаганнарын алып киттеләр. Юрганымны Урта Сабага сеңлем Шәмселхәят төшкәч биреп менгердем. Самоварны, булган тәлинкәләрне (күпме табак - савыт булгандыр инде) чыгарып тиреслеккә күмдем. Чират өйгә житте. Өебез алты почмаклы. Ләкин бер ягы янган, такта белән төрелгән иде. Шуның берсен сүтеп, Сатыш кешесе аласы иде. Авыл кешесе (исемен хәтеренә төшерә алмады) киңәш бирде. Тактасын ачып куй, янганын күрсен, - диде. Сатыш кешесе менде, өйне карады, янганлыгын белгәч алмый төшеп китте. Без шулай өйдән куылмадык”, - дип хатирәләрен яңартты дәү әни.

Атлары булган, колхозга алганнар. “Көн саен чишмәгә су эчәргә алып төшәләр иде. Атның кешни - кешни капка төбендә кычкыруы (кертергә сорап) бүген дә колагымда,” - дип елый - елый сөйли иде.

Сугыш!!! Бу афәт дәү әниләр гаиләсен дә читләп узмый. Фатыйх бабай беренче көннән үк сугышка китә. Шул китү белән кире әйләнеп кайтмый. Дәү әнине сугыш вакытсыз тол итә. Ул бик көчле иде, сынмады, сыгылмады. Авырлыкларны үз җилкәсендә күтәреп, ялгызы төпчек улын аякка бастырды. Дәү әни - гомер буе колхозда төрле эштә эшләгән тыл ветераны, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50 еллыгы юбилей медальләре, 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.

Дәү әни күп еллар авылыбызның абыстае булды. Биш вакыт намазны, бер ел уразаны калдырмады.

Ул 1995 елның 27 апрелендә гүр иясе булды. Юлбат авылына җирләнде.



## Галләмова (Шәмсетдинова) Газанбану Шәмсетдин кызы

1910 елның 5 апрелендә Юлбат авылында туган. Окоп казуда, вагон бушатуда, Шәмәрдәннән симәнә ташуда, көлтә бәйләүдә катнашкан. 21 елгы ачлык михнәтләрен дә күрә. Авырлыкларга бирешми, түзем, чыдам булып гомер итә. Бүген дә иң матур хатирәләре, сагынып сөйләрлек матур сыйфатлары балалары, оныклары күңелендә саклана. Юлбат авылы егете Галләмов Мансур белән тормыш кора. Бер - бер артлы 3 малай туа.

Тыл ветераны. Җиңүнең 30, 40, 50, 55, еллыгы юбилей, 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.

2002 елның 3 маенда вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.

## Якупова Хәбирә Якуп кызы



1919 елда Юлбат авылында туа. Юлбат башлангыч, Сатыш җидееллык, Саба урта мәктәпләрендә белем ала. 1941 елда Югары Симет мәктәбендә хезмәт юлын башлый.

Сугыштан соң Кызыл Мишә башлангыч мәктәбенә укытырга килә һәм, лаеклы ялга чыкканчы, шул мәктәптә укыта. 1965 елда мәктәп мөдире итеп билгеләнә. Күп тапкырлар район мәгариф бүлегенең Мактау грамоталары белән бүләкләнә.



## Сәләхова (Хәбирова) Мәхтүмә Хәбир кызы

1925 елның 12 декабрендә Теneки авылында туган.

“Магнит” колхозында төрле эшләрдә эшләгән.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2010 елның 16 сентябрендә вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.



## Сабирҗанова (Нурмөхәмәтова) Шәмсенур Нурмөхәмәт кызы

1913 елның 4 январенда Тенеки авылында туган.

“Яңа юл” колхозында төрле эштә эшләгән.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2001 елның 3 сентябрендә вафат булган. Тенеки авылына җирләнгән.



## Мөбәрәкшина (Гайфуллина) Мәгъруфә Гайфулла кызы

1914 елда Юлбат авылында туган.

“Ворошилов” исемендәге колхозда төрле эшләрдә эшләгән.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале, Җиңүнең 30, 40 еллыгы юбилей медальләре белән бүләкләнгән.

1988 елның 23 маенда вафат булган. Юлбат авылына җирләнгән.


## Гомәров
## Нургаян Зиннур улы



1931 елның 21 декабрендә Йосыф - Алан авылында туган. “Искра” колхозында төрле эшләрдә эшләгән.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең юбилей, 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен”, “В.И.Ленинның 100 еллык юбилее” медальләре белән бүләкләнгән.

1990 елның 14 ноябренда вафат булган. Йосыф - Алан авылына җирләнгән.



## Нуретдинов
## Гыйльметдин Нури улы

1928 елның 10 декабрендә Калатау авылында туган.

“Искра” колхозында төрле эшләрдә эшләгән.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең юбилей, 1948 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.

2011 елның 6 октябрендә вафат булган. Калатау авылына җирләнгән.



## Гасыймова Нурлыбанат
## Гасыйм кызы

1916 елның 26 декабрендә Саба районы Тенеки авылында туган.

“Яңа юл” колхозында төрле эшләрдә эшләгән.

1941 елның көзендә окоп казырга җибәргәннәр, мартка кадәр кыш буе окопта булганнар. Сугыш вакытында көндезен колхозда авыр эшләрдә эшләргә туры килгән. Төннәрен фронтка носки, бияләйләр бәйләгәннәр.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

1993 елның 28 маенда вафат булган. Тенеки авылына җирләнгән.



## Гасыймов Тимерҗан
## Гасыйм улы

1929 елның 15 июнендә Саба районы Тенеки авылында туган. Тенеки башлангыч мәктәбен тәмамлап, Сабада укый башлагач, сугыш башланган. 1938 елда малайлар белән ат көтә башлаганнар.

Ногманов Нурислам абый МТСка тракторлар ремонтларга эшкә чакыра. 1945 елда колесный тракторда эшли башлый, армиягә киткәнче шунда эшли. Ремонт вакытларында мастерскойны төнге 11 гә кадәр бикләп эшләтәләр иде, - ди күршесе Юныс абый. Армиядән кайткач, комбайнда эшли. Лаеклы ялга чыкканчы, җәен комбайнда, кышын тракторда эшләде. Фермага малларга трактор белән азык ташыды. Фермада слесарь, кочегар, оператор булды. Лаеклы ялга чыккач, хуҗалыктан сөт җыйды. Бригадир һәм инженер булып эшләгән еллары да бар.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2001 елның 14 июнендә вафат булган. Тенеки авылына җирләнгән.



# Баһавиев Сәүбән Баһаветдин улы

Тенеки авылының иң оста көмешчеләреннән саналган Шәмсетдиннекеләр нәселенең дәвамчысы Баһаветдин белән Гөлфәридә гаиләсендә бер-бер артлы дүрт малай һәм бер кыз туа.Нәсел агачының тамыры нык, тармаклы булыр, дип карый авыл халкы.

Юк икән шул... Ата-ана, Ходайдан бәхет һәм тәүфыйк сорап үстергән өч улын - әле гаилә дә корырга өлгермәгән япь-яшь өч егетне сугышка озата. Йортта калган кече малай Сәүбәнгә балалык белән бик иртә саубуллашырга туры килә. Аяусыз сугыштан Ислам абыйсы гына әйләнеп кайта, ике абыйсы үлеп кала.

Баһавиев Сәүбән Баһаветдин улы 1929 нчы елның 1 нче июлендә Тенеки авылында гади колхозчы гаиләсендә туа. Сугыш вакытында тылдагы бөтен авырлык картларга, хатын-кызларга һәм үсмер малайларга-кызларга төшә. “Ярты Саба – минем классташ”,-дия торган була ул шаяртып. Дөрестән дә, күз җиткәч, Саба мәктәбенә укырга меңнәр дә, ике-өч атна укуга, янә авылларында колхоз эшенә чума торган булалар алар. Колхоздагы бөтен авыр эшләрдә эшләргә туры килә аңа. Урман бригадиры, колхоз бригадиры булып та эшли, соңрак, бик озак терлекчелектә эшләп, лаеклы ялга чыккач та, колхозда эшләвен туктатмый.

Тенеки авылы кыза Сания белән гаилә корып, сигез бала тәрбияләп үстерәләр. “Әти - эшчән, гадел, туган җанлы, туры сүзле, таләпчән кеше иде. Ул безне шыңшымаска, тырыш булырга, эшләп ашарга өйрәтте”,- дип искә ала балалары. Дүрт кызы Сабада, бер кызы Сатыш авылында, бер кызы Чаллы шәһәрендә үз гаиләләре белән гомер кичерәләр. Олы улы 2010 нчы елда йөрәк авыруыннан вакытсыз вафат була. Бүгенге көндә төпчек улы Зөфәр төп нигездә гаилә корып яши һәм колхозда тракторда эшли.

Тыл ветераны. 1947 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

Баһавиев Сәүбән Баһаветдин улы 2008 нче елның 10 нчы апрелендә вафат була. Тенеки авылына җирләнгән.



## Галиева (Сабирова) Мәхтүмә Сабир кызы

Мамадыш районы Ишки авылында 1925 елның 15 сентябрендә туа.

1940 -1945 елларда Ишкидә ипи пешерүче булып эшли. 1945-1955 елларда Ишки авылында сыер савучы хезмәтен башкара.

1955 елның мартында Саба районы Юлбат авылы егете Галиәхмәтов Фарук белән тормыш корып, 6 бала тәрбияләп үстерәләр. (17 оныгын, 12 оныкчыгын күрү бәхетенә ирешә). 1972-1984 елларда “Искра” колхозында пешекче булып эшли. Улы Шамил, килене Нәкыя гаиләсендә 89 яшен тутырып, 2014 елның 16 ноябрендә дөнья куя. Юлбат авылына җирләнә.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55, 60, 65 еллыгы юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.



## Галиәхмәтов Фарук Галиәхмәт улы

1927 елның 1 апрелендә Саба районы Юлбат авылында (Галиәхмәт белән Хәтирәнең өлкән уллары) туа.

1941 елда Сатыш җидееллык мәктәбен “5” ле билгеләренә генә тәмамлый.

1941-1943 елларда Саба урта мәктәбендә укыта. 1943-1945 елларда Саба саклык банкында эшли.

1955 елның мартында Мамадыш районы Ишки авылы кызы Сабирова Мәхтүмә белән тормыш корып, 6 бала тәрбияләп үстерәләр. 1945-1971 елларда Саба, Туктар, Юлбат кибетләрендә сатучы булып эшли. 1971-1987 елларда Саба “Дом быта” да склад мөдире вазифасын алып бара.

Тыл ветераны. 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен”, Бөек Җиңүнең 30, 40, 50 еллыгы юбилей медальләре белән бүләкләнә.

1997 елның 17 июлендә вафат була. Юлбат авылына җирләнә.



## Иманкулова Газзә

1903 елда Тәкәнеш районы (хәзерге Мамадыш ) Вахит авылында мулла гаиләсендә туа. Аның башта әнисе, Газзәгз 3 яшь булганда, әтисе үлә. Бертуган абыйсы Мирзагабдулла Газзәне үз тәрбиясенә ала. Абыйсы Газзә белемле, укымышлы булсын дип тырыша, аны укытучылар әзерли торган курсларга укырга бирә. Бу курсларны тәмамлап, ул Юлбатка укытучы булып килә.

Газзә Иманкулова авылда 28 ел балаларга белем бирә. Актив комсомолка үзешчән сәнгатьтә дә катнаша. Авылыбыз егете Мөхәмәтҗанов Һадиулланы үзенә тормыш иптәше итеп сайлый. Алар 1930 елда өйләнешәләр һәм 1942 елга кадәр бик матур яшиләр, ләкин балалары булмый. 1942 елда Һадиулла сугышка китә һәм кире әйләнеп кайтмый. Газзә ирен гомеренең соңгы көннәренә кадәр көтә.

Газзә Иманкулова бик тыйнак, сабыр, итагатьле, тырыш укытучы була. Тырыш хезмәте өчен 1939 елда “Кызыл байрак” ордены, “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале, 1952 елда Ленин орденына лаек була. Гомеренең соңгы елларын Газзә апа туган авылында үткәрә. 1987 елда вафат була. Мамадыш районы Вахит авылына җирләнгән.



## Зәйнуллина (Галимуллина) Гөлмәдинә Галимулла кызы

1919 елның 10 июнендә Югары Шытсу авылында туган.

“Искра “ колхозында гомер буе умартачы булып эшләгән.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55 еллыгы юбилей, 1948 елда “1941-45 батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.

2002 елның 30 ноябрендә вафат була. Калатау авылына җирләнгән.



# Сабирова (Галимҗанова) Гөлмәдинә Галимҗан кызы

1919 елның 25 декабрендә Тенеки авылында Галимҗан белән Хөсникамал гаиләсендә икенче бала булып туа. Әтиләре яшьләй авырып үлә, алты бала белән әниләре тол кала. Яшьләй авырлыкларны күреп, эшләп үсә. Сугыш алдыннан 19 яшьлек кызны, өч авылдаш кыз белән Тула шәһәренә хәрби заводка эшкә җибәрәләр. Шунда эшләгәндә Бөек Ватан сугышы башлана. Тула шәһәрен бомбага тота башлагач, алар кайтып китә. “ 1 ай җәяү кайттык, ачлы-туклы чак авылга кайтып егылдык. Хәлебез начар иде. Сугыш вакыты, иркәләнеп ятып тора торган чак түгел, законнар каты. Илгә, фронтка икмәк кирәк. Без колхозга эшкә чыктык. Хәзер дә аптырап утырам. Нигә безне эзләтмәделәр икән. Хәрби заводтан киттек бит без, рөхсәтсез. Безне бомбага эләгеп үлгәннәр дип уйлаганнардыр, мөгаен,” - дип искә ала ул чакларны.

Сугыштан соң, аны чакырып алып, Тенеки авылына кибеткә сатучы итеп билгелиләр. Байлар Сабасында, Мәртендә, Юлбат авылларында төрле елларда кибеттә сатучы булып эшли. Эшләгән чакта бирелгән мактау граматолары, аның эшкә җаваплы караганы, намус белән хезмәт иткәнен сөйли. 1948 елда Бөек Ватан сугышы чорында 1941-45 елларда тылда фидакарьләргә эшләгән өчен “ Хезмәтәге батырлыгы өчен” медале, 1970 елда В.И.Ленинның 100 еллыгы уңае белән чыгарылган “Хезмәттәге батырлыгы өчен” медале, Бөек Җиңүнең 30,40, 50, 55,60 еллык юбилей медальләре белән бүләкләнә. Тыл һәм хезмәт ветераны.

1951 елда сугыш ветераны Хатмулла белән тормыш корып җибәрә. Ярты гасыр бергә яшәп, 2 ул, 1 кыз тәрбияләп үстерәләр. Оныкларны көтеп алалар. 9 оныкны бергәләп үстерәләр, оныкчыкны сөю бәхетенә ирешәләр.

Кайнатасы Мөхәмәтсабир килене Мәдинә белән өч ел гына яшәп кала, авырып үлә. Кайнанасы Бибигалияне зурлап, олылап, хөрмәтләп, 47 ел бергә яшиләр.

Үзе дә төп йортта улы Хәлил, килене Гөлсинә тәрбиясендә тату, матур яшәделәр.

2006 елның 10 февралендә вафат булды. Тенеки зиратына җирләнде.



## Сафина (Кәшипова)
## Нажия Кәшип кызы

1931 нче елның 22 апрелендә Юсуф-Алан авылында туа. Сугыш башлангач, әтисен сугышка алып китәләр. Ул яу кырларында ятып кала. Әнисе Мәймүнә җилкәсендә 5 бала кала. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала. Аннан Сатыш мәктәбендә 7 класска кадәр укый. Математика иң яраткан фәне була. Кечкенәдән әнисенә булышып үсә ул. Басуда көлтә бәйләргә йөргән, урак урган, печән чапкан, молотилкада ашлык суктырган. Күп еллар амбар мөдире булып эшләгән.

1954 нче елда авыл егете Сафин Раян белән тормын корганнар. Ике ул һәм бер кыз тәрбияләп үстергәннәр. 1993 нче елны каты авырудан соң вафат була. Юсыф-Алан авылына җирләнгән.



## Низамиева (Кәримова)
## Рәкыя Кәримовна

1928 елның 15 июлендә Саба Юлбат авылында туган.

Сатыш мәктәбендә 7 класс белем ала. 1942-1949 елларда колхозда счетовод булып эшли. 1949 -1951 елларда Саба урта мәктәбендә счетовод булып эшли. 1951-1967 елларда Шекше колхозында - колхозчы. 1975 – 1985 елларда Юлбат авылында элемтә бүлеге начальнигы вазифасын башкара.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50 еллыгы юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.

2003 елның 28 августында вафат була. Юлбат авылына җирләнгән.




## Фәтхриев
## Рухылбаян Фәтхрахман улы

1931 нче елның 12 нче мартында Юлбат авылында гади колхозчы гаиләсендә туа. Сугыш вакытында тылдагы бөтен авырлык картларга, хатын-кызларга һәм үсмер малайларга-кызларга төшә. Колхоздагы бөтен авыр эшләрдә эшләргә туры килә аңа. Ындыр табагында ашлык суыруда, кыр эшләрендә катнаша. 1944 нче елларда 13 яшьлек малай урман эшләрендә эшли, такта яра. Армия сафларында хезмәт итеп кайткач, комбайнда эшли. 1957 нче елда шоферлар курсы бетереп кайтып, озак еллар шофер булып эшли. Буш вакытларында итек басу белән шөгыльләнә.

Балык Бистәсе районы Әшнәк авылы кызы Рәхимә белән тормыш корып, өч ир бала тәрбияләп үстерәләр. Олы улы Ленинград өлкәсе Кронштадт шәһәрендә, икенче улы Байлар Сабасында, өченче улы Юлбат авылында үз гаиләләре белән гомер кичерәләр.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50 еллыгы юбилей, 1993 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнә.

1997 нче елның 15 мартында вафат була. Юлбат авылына җирләнә.



## Галләмов
## Равил Рәшит улы

1930 елның 17 августында Тенеки авылында туган.

“Искра” колхозында гомер буе тракторчы булып эшләгән.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50 еллыгы юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медальләре белән бүләкләнгән.

1998 елның 5 ноябрендә вафат булган. Тенеки авылына җирләнгән.




## Тимербаева (Абдуллина) Мөнәвәрә Абдулла кызы

1930 елның 15 мартында Алан - Җөри авылында туган. Әтисе Кәримуллин Абдулла 1941 елда сугышка алынган. 1946 елда сугыштан кайткан. Мөнәвәрә апага сугыш башланганда 11 яшь булган. Ат белән Шәмәрдәнгә агач ташыган. Сугыш беткәч, ат белән чәчү чәчкәннәр, урак урганнар, көлтә җыйганнар. 1947 елда тракторда эшләгән. 1962 - 1985 елларга кадәр “Искра” колхозында терлекчелектә эшләгән. 1984 елның 27 январенда “Иң яхшы терлекче” исеме бирелгән.

Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең юбилей, 1995 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен”, “Ударник девятой пятилетки” медальләре белән бүләкләнгән.

2011 елның 26 мартында вафат булган. Йосыф-Алан авылына җирләнгән.



## Тимербаев Мәдехәт Нургаяз улы

1930 елның 1 июлендә Йосыф-Алан авылында туган.


Сугыш башланганда, аңа 11 яшь булган. Сугыш вакытында ат белән сука сукалаган, чәчү чәчкән, урак урган. Иштуган станциясендә агач чыгаруда катнашкан.

“Искра” колхозында төрле эшләрдә эшләгән. Тыл ветераны. Бөек Җиңүнең юбилей, 1948 елда “1941-45 еллардагы батыр хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

2012 елның 25 маенда вафат булган. Йосыф-Алан авылына җирләнгән.



**Сугышта һәлак булучылар истәлегенә
1967 елда куелган беренче обелиск**



**Сугышта һәлак булучылар истәлегенә куелган обелиск
1987 елда ясалган реконструкциядән соң**






**Сугышта һәлак булучылар истәлегенә
2014 елда төзелгән яңа обелиск**